СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за "Мамадышский",
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
"20" ноября 2018 г.

Карар
№ 4-37

## 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдумда кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 апрелендәге № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

-авылларда юллар төзекләндерү

Мамадыш совхозы поселогы Банк тыкрыгы,

Мамадыш совхозы поселогы Тукай тыкрыгы ,

Кызыл Тау авылы Котып урамы ,

Керәшен Пакшины авылы Тынычлык урамы,

Мамадыш совхозы икенче номерлы Ферма поселогы Гагарин урамы.

-Кызыл Тау авылында җәяүлеләр өчен салынган күперләр төзекләндерү;

-Күперләр төзекләндерү:

Максим Пучинкәсе авылы, Ташлы авылы , Мамадыш совхозы икенче номерлы Ферма поселогындагы;

- авыл җирлегенә карауч<del>ы</del> юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

2. Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру:
урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (урам яктырткычларын төзек хәлдә тоту, сатып алу һәм яңага алыштыру).

4. Җирлек халкының бергә җыелып ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның җыелып ял итү урыннарын төзекләндерү, гражданнарның гомуми

файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле керә алуын тәэмин итү:

-Кызыл Тау авылында һәм Мамадыш совхозы икенче номерлы Ферма поселогында балалар мәйданчыклары урнаштыру;

« ӘЙЕ » « ЮК »

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 908 номерлы карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Кызыл Тау
авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе В.А.Гиззатуллина

СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001027